Татарстан Республикасы Хисап палатасы

Татарстан Республикасы Хисап палатасының 2020 елдагы эшчәнлеге турында Хисап

Казан – 2021 ел

Эчтәлек

Тикшерү-ревизия эшчәнлеге .....……..…….....…3

Экспертиза-аналитика эшчәнлеге....……..…….....20

Эшчәнлекне методологик яктан тәэмин итү.....…….……31

Россия Федерациясе Хисап палатасы, Россия Федерациясе Хисап палатасы каршындагы Тикшерү-хисап органнары советы, Россия Федерациясе субъектлары тикшерү-хисап органнары белән үзара хезмәттәшлек…….....32

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре тикшерү-хисап органнары белән хезмәттәшлек ...……..……...…..37

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте һәм хокук саклау органнары белән хезмәттәшлек .....…….....39

Эшчәнлектә хәбәрдарлык.....41

Татарстан Республикасы Хисап палатасының 2020 елдагы эшчәнлеге турында Хисап

Татарстан Республикасы Хисап палатасы (алга таба – Хисап палатасы) эшчәнлеге турында хисап Татарстан Республикасының 2004 елның 7 июненнән «Татарстан Республикасы Хисап палатасы турында» Законының 33 маддәсе нигезендә әзерләнде.

Хисапта Хисап палатасының 2020 елда закон тарафыннан билгеләнгән бурычларны һәм вәкаләтләрне үтәү буенча эшчәнлеге нәтиҗәләре тәкъдим ителде.

Тикшерү-ревизия эшчәнлеге

Хисап елында Хисап палатасы тарафыннан 47 тикшерү-ревизия чарасы уздырылды, 474 объект тикшерелде.

«Куркынычсыз һәм сыйфатлы автомобиль юллары», мәктәпкәчә белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында 2 айдан 3 яшькә кадәрге балалар өчен өстәмә урыннар булдыру өлешендә «Демография», «Демография – Өлкән буын», «Сәламәтлек саклау», «Мәгариф» илкүләм проектларын тормышка ашыруны тикшерүдә тоту кысаларында тикшерүләр үткәрелде.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы йөкләмәсе буенча 2 тикшерү чарасы уздырылды.

Сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен мәктәп-интернатлар эшчәнлеген тәэмин итүгә бүлеп бирелгән бюджет чараларын куллануның нәтиҗәлелек аудиты нәтиҗәләре буенча республиканың кайбер мәктәп-интернатларына 4 726,6 мең сумлык ит һәм сөт продукциясенең аерым төрләрен китерүнең товарның дәүләт контрактлары таләпләренә туры килүен (тиешле ГОСТ күрсәтмәсеннән башка) расламыйча башкарылуы ачыкланды.

Бюджет (бухгалтерия) исәбенә, шул исәптән бюджет, бухгалтерия (финанс) хисаплылыгын төзү, тапшыру буенча закон таләпләрен бозу фактлары буенча 26 345,5 мең сумлык административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзелде.

Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының табигать ресурсларыннан файдаланган өчен түләүләрне администрацияләү буенча бюджет вәкаләтләрен үтәвен тикшерү аерым җир асты байлыкларыннан файдаланучылар тарафыннан бер тапкыр түләнә торган түләүләрне түләмәү нәтиҗәсендә, республика бюджетына 5 151,4 мең сум күләмендә акча кермәү ачыкланды. Тикшерү уздыру вакытына Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы материалларында гомумтаралган файдалы казылмаларны рөхсәтсез эшкәртүнең 449 факты турында мәгълүмат тупланган иде, алар файдалы казылмалар чыгаруга салым, ятмаларны эшкәртүгә хокук биргәндә бер тапкыр түләүләр, эшкәртелә торган җир кишәрлекләре өчен аренда түләве рәвешендә бюджет системасына акча кермәүгә китерә.

Файдалы казылмаларны санкциясез чыгару фактларының шактый күп булуы, шул исәптән җирле үзидарә органнарының 2003 елның 6 октябреннән «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законда каралган җир тикшерүен гамәлгә ашыру вәкаләтләрен тиешенчә үтәмәве белән дә бәйле булырга мөмкин. Мәсәлән, республиканың бары тик 26 муниципаль берәмлегендә генә җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендә муниципаль җир тикшерүен гамәлгә ашыру буенча муниципаль функцияләрне үтәгәндә административ процедураларның һәм гамәлләрнең вакытларын һәм эзлеклелеген билгеләүче норматив хокукый актлар кабул ителде.

Татарстан Республикасы Прокуратурасы йөкләмәсе буенча Хисап палатасы Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгында һәм Татарстан Республикасы Икътисад

министрлыгында «Халыкара кооперация һәм экспорт», «Кече һәм урта эшмәкәрлек һәм шәхси эшмәкәрлек инициативасына ярдәм» илкүләм проектларын гамәлгә ашыруның барышын тикшерүдә катнашты.

Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре буенча идарәсе эксперт группасы составында Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгында, «Челтәр компаниясе» ААҖ, Әлки, Әтнә, Чүпрәле, Чирмешән муниципаль районнарында коррупциягә каршы чараларны гамәлгә ашыруда практик ярдәм күрсәтү буенча комплекслы чаралар үткәрүдә катнашты.

Татарстан Республикасында Терроризмга каршы комиссия белән берлектә Хисап палатасы Татарстан Республикасы Спорт министрлыгында, Буа, Яшел Үзән, Яңа Чишмә һәм Чирмешән муниципаль районнарында тикшерүләрдә катнашты.

Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Икътисадый куркынычсызлык һәм коррупциягә каршы тору идарәсе белән берлектә «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика наркология диспансеры» ДАССОның 2019 елда һәм 2020 елның үткән вакыт аралыгында бүлеп бирелгән Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын куллануны тикшерү буенча тикшерү чарасы үткәрелде.

Татарстан Республикасы бюджеты, Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминиятләштерүе фонды (алга таба – Татарстан Республикасы ММИ Территориаль фонды) үтәлешенең аерым мәсьәләләре, дәүләт һәм муниципаль милекне куллануның аерым мәсьәләләре буенча тикшерү чаралары Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгында, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгында, Татарстан Республикасы Җир һәм милек мөнәсәбәтләре министрлыгында, Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгында һәм алар карамагындагы учреждениеләрдә, «Татмедиа» Республика матбугат һәм

массакүләм коммуникацияләр агентлыгында, Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетында, «Татарстан Республикасы Баш инвестиция-төзелеш идарәсе» ДКУ, «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы каршындагы Юл-транспорт комплексын тоту һәм үстерүнең баш идарәсе», «Татарстан Республикасы Милли музее» ДБМУ, «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика кан үзәге» ДАССУ, «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының академик В.М.Бехтерев исемендәге Республика клиник психиатрик хастаханәсе» ДАССУ дә, республиканың Аксубай, Югары Ослан, Кайбыч, Менделеевск, Тукай муниципаль районнарында үткәрелде.

«Татарстан Республикасының Геология һәм җир асты байлыкларыннан файдалану буенча фәнни-җитештерү берләшмәсе» ДУП, «Элита» Баш нәсел предприятиесе» АҖнең финанс-хуҗалык эшчәнлеге тикшерелде.

Үткәрелгән тикшерү чаралары нәтиҗәләре буенча **3 384 719,1** мең сумлык **хокук бозулар ачыкланды**, шул исәптән: Татарстан Республикасы бюджеты чаралары буенча – 1 896 857,8 мең сум, муниципаль берәмлекләр бюджетлары буенча – 1 449 655 мең сум, Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фонды – 32 946,7 мең сум, башка чаралар буенча – 5 259,6 мең сум.

2020 елда үткәрелгән тикшерү чаралары барышында Хисап палатасы тарафыннан ачыкланган финанс бозуларның төзелеше

мең сумнарда



- бюджет чараларын һәм дәүләт (муниципаль) милкен нәтиҗәсез файдалану – 1 062 668,8 мең сум;

- дәүләт (муниципаль) милкеннән файдаланганда һәм эш иткәндә хокук бозулар – 452 686,6 мең сум;

- бухгалтерлык исәбен алып баруны, бухгалтерлык (финанс) хисабын төзү һәм бирүне бозулар –388 919,3 мең сум;

- дәүләт (муниципаль) сатып алуларны гамәлгә ашырганда бозулар – 235 057,6 мең сум;

- бюджет чараларын максатсыз файдалану – 826,5 мең сум.

Россия Федерациясе Җинаять кодексының 159 статьясындагы 3 өлеше буенча (Минзәлә шәһәрендә М.Җәлил исемендәге парк территориясендә элмә такталар ясау буенча башкарылган эшләрнең бәясен арттыру факты буенча ачыкланмаган затларга карата) җинаять эше кузгатылды.

Хисап палатасы тарафыннан үткәрелгән тикшерү чаралары нәтиҗәләрен гомумиләштерү түбәндәге системалы бозуларны ачыкларга мөмкинлек бирә.

Бюджетларны формалаштырганда һәм үтәгәндә бозулар.

Татарстан Республикасында дәүләт (муниципаль) программаларын гамәлгә ашыру, гражданнарның аерым категорияләренә акчалата түләүләр бирү тәртибен бозулар.

Ятим балаларга һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларга ярдәм итү чаралары күрсәтү өчен бүлеп бирелгән Татарстан Республикасы бюджеты акчаларыннан максатчан һәм нәтиҗәле файдалануны тикшерү барышында 2018-2019 елларда Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы тарафыннан ятим балалар өчен махсуслаштырылган торак фондын формалаштырганда билгеләнгән норматив тан кимрәк мәйданлы 186 фатир сатып алынуы ачыкланды. Ятим балаларга бирелгән махсус торак фондының торак биналары мәйданы 26дан 42,9 кв. метрга кадәр, аерым очракларда – 1,6 тапкырдан артык аерма белән аерылып торды. Шул ук вакытта законнар мондый бинаны социаль яллау шартнамәсе буенча аны, биш еллык узгач, биләгән затка тапшыруны күздә тота.

Шуңа бәйле рәвештә, ятим балалар өчен элек сатып алынган фатирларның мәйданнарының билгеләнгән нормативларга туры килмәве ятим балалар өчен кабат мәйданы законнар таләпләренә туры килә торган торак урыннары сатып алу өчен бюджетның өстәмә чыгым ясау куркынычына китерә.

Югарыда күрсәтелгән бюджетның өстәмә чыгымнар куркынычын юкка чыгара торган карарлар кабул итү өчен мәгълүмат Татарстан Республикасы Президентына җибәрелде. Тикшерү материаллары Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына юлланды, алар тарафыннан ятим балалар өчен сатып алына торган торак урыннарының мәйданы характеристикалары диапазонының дәүләт контрактларын төзегәндә, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре тарафыннан күрсәтелгән категориядәге гражданнарның торак урыны мәйданын бирү нормалары нигезендә, тайпылышсыз үтәү турында карар кабул ителде.

Автомобиль, шәһәр транспортын үстерүгә бүлеп бирелгән Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын куллануны тикшерү нәтиҗәсендә муниципаль берәмлекләрнең бердәм айлык социаль йөртү билеты һәм балалар өчен бердәм айлык социаль йөртү билеты буенча транспорт хезмәтләре күрсәткән өчен гражданнарга компенсация түләүләре турында исәп-хисапларны үз вакытында тапшырмаулары нәтиҗәсендә гомуми суммасы 2 602,1 мең сум булган компенсацияне ай саен күчерүнең Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 10 мартыннан 134 номерлы карары белән расланган субсидияләр бирү тәртибе нигезендә билгеләнгән регулярлык принцибы үтәлмәгән.

Сыер абзарларын, яшелчә

саклагычларын, силос-сенаж траншеяларын капиталь ремонтлау һәм төзүгә бүлеп бирелгән бюджет акчаларын куллануны тикшерү сыер абзарларына капиталь ремонт ясау буенча эшләрне башкару өлешендә авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә финанс ярдәме «Татарстан Республикасының Баш инвестиция-төзелеш идарәсе» ДКУ тарафыннан төзелгән дәүләт контрактлары нигезендә гамәлгә ашырылуын билгеләде. Шул ук вакытта капиталь ремонт ясалырга тиешле объектларны сайлап алу критерийлары республиканың норматив хокукый актлары белән билгеләнмәгән, Татарстан Республикасы бюджеты чаралары исәбеннән финанс кертемнәре Россия Федерациясе Бюджет кодексының 80 маддәсендә билгеләнгән таләпләрне бозып, аларны бюджет инвестицияләре сыйфатында рәсмиләштермичә гамәлгә ашырылган. Бюджет акчалары хисабына капиталь ремонт ясалган авыл хуҗалыгы объектлары хуҗаларының йөкләмәләренә карата җайга салуның булмавы 4 сыер абзарын буш тору фактлары буенча чаралар күрү өчен нигезләрнең булмавына китерде, аларны ремонтлауга республика бюджетыннан 4 776,1 мең сум акча тотылган.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым күрсәтмәләре нигезендә, сыер абзарларына капиталь ремонт республика бюджетыннан һәм бюджеттан тыш чыганаклардан финанслауда катнашу шартларында гамәлгә ашырыла. Бюджеттан тыш чыганаклардан финанслаштыру шартларын үтәүне бәяләү авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләрнең чыгымнарын дөрес раслый торган документлар булмау сәбәпле мөмкин булмады.

Хисап палатасы авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләрнең ремонт эшләрен финанслау чыгымнарын раслау бурычын беренчел документлар (эшләр башкаруга һәм хезмәтләр күрсәтүгә килешүләр, башкарылган эшләр актлары, накладнойлар h.б.) белән беркетергә тәкъдим итте.

Субсидия алучылар тарафыннан авыл хуҗалыгы обүектларын төзү һәм капиталь ремонтлау буенча эшләрне башкарган чакта килеп чыккан

чыгымнарның бер өлешен каплау өчен (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 39 ноябрендә кабул ителгән 1068, 1069 номерлы, 2019 елның 15 февралендә кабул ителгән 106 номерлы карарлары тарафыннан расланган Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе нигезендә) нәтиҗәлелек күрсәткеченә ирешү турында хисаплар тапшырмауның күпсанлы очраклары ачыкланды. Хисаплар булмау, һәм шуның аркасында дәүләт ярдәме чараларының нәтиҗәлелеген анализлауны үткәрә алмау авыл хуҗалыгы тармагында тормышка ашырыла торган дәүләт программаларының аерым чараларын үтәүнең нәтиҗәлелеген бәяләүне үткәргән чакта тискәре йогынты ясарга мөмкиннәр.

«Элита» баш нәсел предприятиесе» АҖ финанс-хуҗалык эшчәнлеген тикшерү нәтиҗәсендә тикшерелгән чорда предприятиегә ясалма орлыкландыру җиһазлары сатып алу белән бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен 22 307,6 мең сум күләмендә субсидия бүлеп бирелүе ачыкланды. Республика бюджетыннан каплау 2018 елда җиһазлар бәясенә карата – 70% һәм 2019 елда 40% тәшкил иткән. Сатып алынган җиһазларның бер өлеше чынлыкта кулланылмаган, ә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр алу өчен билгеләнгән таләпләргә туры килмәгән башка авыл хуҗалыгы предприятиеләре тарафыннан файдаланылган. Җиһазны яңадан сату, республика бюджетыннан алынган субсидиясен исәпләмәгәндә, өстәмә хак белән башкарылган.

Хисап палатасы тарафыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 26 гыйнварында кабул ителгән 42 номерлы субсидияләр бирү тәртибен көйли торган карарына тиешле үзгәрешләр кертүнең субсидия алырга хокукы булган авыл хуҗалыгы җитештерүчеләре даирәсен киңәйтү максатында урынлы булуы билгеләп үтелде.

Акча чараларының республика, муниципаль берәмлек бюджетына кереп җитмәве.

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районында узган тикшерү чаралары барышында җирле бюджет тарафыннан җир салымын һәм милеккә керем салымын түләү буенча вакыты чыккан бурычлар җибәрү нәтиҗәсендә гомуми күләме – 15 948,5 мең сум, шулай ук җир кишәрлекләре өчен аренда түләве буенча гомуми күләме 3 774,5 мең сумлык акчалата чараларны җыеп ала алмаганнар.

Дәүләт (муниципаль) органнар, автоном һәм казна учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт хакын түләү тәртибен һәм шартларын бозу

«Яңа коронавирус инфекциясе ачыкланган гражданнарга һәм яңа коронавирус инфекциясе йоктыру куркынычы булган төркемгә кергән затларга медицина ярдәме күрсәтә торган медицина оешмалары хезмәткәрләренең аерым эш шартлары һәм өстәмә йөкләмә алган өчен стимуллаштыра торган федераль түләүләрен тормышка ашыруны мониторинглау» тикшерү чарасы тарафыннан медицина хезмәткәрләренә гомумән алганда 462,2 мең сум күләмендә стимуллаштыру өчен өстәп түләүләр тулы күләмдә башкарылмаганлыгы ачыкланды (Казан шәһәренең «7 нче номерлы шәһәр клиник хастаханәсе» ДАССУ – 376,1 мең сум, «Республика клиник хастаханәсе» ДАССУ – 11,1 мең сум, Казанның «Ашыгыч медицина ярдәме станциясе» ДАССУ – 75 мең сум).

Тикшерү чаралары нәтиҗәсе буенча Казанның «Ашыгыч медицина ярдәме станциясе» ДАССУ вазыйфаи заты дисциплинар җаваплылыкка тартылды. Медицина учреждениеләрендә стимул рәвешендәге түләүләрне тормышка ашырган чакта җибәрелгән бозуларның сәбәбен һәм шартларын юкка чыгару буенча чаралар күрелгән.

Бюджет классификациясен куллану тәртибен бозу.

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында бюджет чараларын, дәүләт һәм муниципаль милекне файдалануны тикшерү

барышында Кайбыч муниципаль районы һәм Чүти авыл җирлеге башкарма комитетлары Россия Федерациясе Финанс министрлыгының 2013 елның 1 июленнән 65н номерлы боерыгы белән расланган Россия Федерациясе бюджет классификациясен куллану тәртибе турындагы күрсәтмәләрне бозып, бюджет классификациясенең маддәләренә туры килми торган 499,4 мең сум күләмендә чыгымнар тотылуын ачыклады.

Дәүләт (муниципаль) милкеннән файдаланганда һәм эш иткәндә хокук бозулар.

Озак вакыт файдаланылмый торган күчемсез милек объектларын хуҗалык әйләнешенә кертү буенча чаралар күрмәү.

Татарстан Республикасы Президенты йөкләмәсе нигезендә Хисап палатасы муниципаль тикшерү-хисап палаталары белән берлектә муниципаль милектәге файдаланылмый торган милекне әйләнешкә кертү буенча тикшерү үткәрде.

1 863 файдаланылмый торган, шул исәптән 765 төп чаралар объектлар,
797 казна милке объектлары,
7 төгәлләнмәгән төзелеш объектлары, 294хуҗасыз объект ачыкланды.

Файдаланылмый торган мөлкәтне хуҗалык әйләнешенә кертү буенча юл карталары республиканың 6 муниципаль берәмлегендә кабул ителгән, 39 сында юл карталары юк яки эшләү процессында булган.

Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына озак вакытлы һәм ташламалы нигездә ия булу һәм (яки) файдалану хокукында бирү өчен исемлеккә 292 объект, яки файдаланылмый торган муниципаль мөлкәтнең 18,6 проценты кертелгән.

Тикшерү нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына Татарстан Республикасы дәрәҗәсендә файдаланылмый торган объектлар реестрын формалаштыру һәм куллану тәртибен билгели торган норматив хокукый акт кабул итү инициативасы тәкъдим ителде, шул исәптән:

- дәүләт (муниципаль) заказчылары тарафыннан яңа төзелешне планлаштыру алдыннан файдаланылмый торган объектларны капиталь ремонтлау яки реконструкцияләүнең мөмкинлеге һәм максатка ярашлылыгы буенча анализ үткәрү;

- файдаланылмый торган объектлар турында мәгълүматны Интернет челтәрендә урнаштыру.

Җир ресурслары белән идарә итү һәм куллану белән бәйле хокук бозулар.

Татарстан Республикасының Менделеевск муниципаль районында җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре өлкәсендә, шул исәптән аренда түләве күләмен, муниципаль милекне файдалануның нәтиҗәлелеген билгеләү өлешендә бозулар һәм кимчелекләр билгеләнде. Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җир кишәрлекләре, аренда килешүләрен рәсмиләштермичә файдаланылган торак пункт җирләре ачыкланды. Районның Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы тикшерүе барышында 16 авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесенә гомуми бәясе 201,4 мең сум булган дәгъва хатлары җибәрелде, шулай ук 153,3 мең сумлык җир кишәрлеген сату-алу килешүе төзелде.

Аксубай муниципаль районында авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр аренда килешүләрен рәсмиләштермичә файдаланылган.

Дәүләт (муниципаль) сатып алуларын гамәлгә ашырганда хокук бозулар.

Контрактның башлангыч максималь бәясен формалаштырганда, матди кыймматләрне сатып алганда закон таләпләрен үтәү тәртибен бозу.

2017-2019 елларда мәдәният, сәнгать өлкәсендә грантлар түләүгә бүлеп бирелгән Татарстан Республикасы бюджеты акчаларыннан максатчан һәм нәтиҗәле файдалануны тикшерү нәтиҗәләре буенча гомуми бәясе 57 091 мең сум булган концерт чаралары күрсәтүгә контрактлар һәм шартнамәләрне («Муса Җәлил исемендәге Татар академия дәүләт театры» ДБУ – 49 191,7 мең сум, «Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе» ДБУ – 6 846,6 мең сум, «Галиәскәр Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры» ДБУ – 1 052,7 мең сум) аларны гамәлдә башкарганнан соң төзү фактлары билгеләнде.

Төзелеш эшләренең бәясен арттыру, башкарылмаган эшләр өчен түләү.

Сыер абзарлары, яшелчә саклагычлары, силос-сенаж траншеяларын капиталь ремонтлауга һәм төзүгә бүлеп бирелгән бюджет акчаларын куллануны тикшерү нәтиҗәсендә аерым сыер абзарларына капиталь ремонт ясаганда гомуми суммасы 1 378,5 мең сум булган чынбарлыкта үтәлмәгән эшләр кабул ителүе һәм түләнгән булуы ачыкланды. Шулай ук авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә капиталь ремонт һәм төзелеш чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр күләмен исәпләгәндә, гомуми суммасы 3 196,3 мең сумлык чынбарлыкта башкарылмаган эшләр исәпкә алынган.

Бухгалтерлык исәбен алып бару, бухгалтерлык (финанс) хисабын төзү һәм тапшыру кагыйдәләрен бозу.

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында Россия Федерациясе Финанс министрлыгының 2010 елның 1 декабреннән 157н номерлы боерыгы белән расланган дәүләт хакимияте органнары (дәүләт органнары), җирле үзидарә органнары, бюджеттан тыш дәүләт фондлары белән идарә итү органнары, дәүләт (муниципаль)

учреждениеләре өчен бухгалтер исәбенең бердәм планын куллану буенча инструкцияне бозу очраклары ачыкланды. Районның гомуми белем бирү учреждениеләренең бухгалтерлык исәбе буенча «Таттелеком» ААҖ һәм «Россия Почтасы» АҖ нә арендага бирелгән бәясе 415,3 мең сум булган биналарның, «Скулавто» ҖЧҖ нә – бәясе 20 160,8 мең сум булган мәктәп автобусларының бәясе чагылдырылмаган. Бухгалтерлык исәбен һәм хисаплылыгын тупас бозу фактлары буенча тикшерелгән учреждениеләрнең вазыйфаи затларына карата административ хокук бозулар турында 6 беркетмә төзелде.

«Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика кан үзәге» ДАССО балансында 2017 елның 1 гыйнварыннан бирле Түбән Кама ш., Менделеев ур., 32А йорты адресы буенча урнашкан 170,8 кв. метр мәйданлы һәм бәясе 3 231,1 мең сум булган торак булмаган бина чагылыш тапмаган.

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының бухгалтерлык исәбе буенча «тәмамланмаган төзелеш» объектлары составында гомуми бәясе 20 376,1 мең сум булган кулланыла һәм эксплуатацияләнә торган объектлар (һәйкәлләр, мемориаль такталар) саналды.

Бюджет чараларын максатсыз файдалану.

2017-2019 елларда мәдәният, сәнгать өлкәсендә грантлар түләүгә бүлеп бирелгән Татарстан Республикасы бюджеты акчаларыннан максатчан һәм нәтиҗәле файдалануны тикшерү нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 3 февралендә кул куелган 60 номерлы карары нигезендә бүлеп бирелгән мәдәният, сәнгать һәм кинематография өлкәсендә Татарстан Республикасы Президенты грантлары хисабына иҗади проектта һәм чыгымнар сметасында каралмаган, грант бирү максатларына туры килми торган «Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе» ДБУ 725 мең сумлык, «Муса Җәлил исемендәге Татар академия дәүләт опера һәм балет театры» ДБУ тарафыннан гомуми суммасы 101,5 мең сумлык чыгымнар тотылуы билгеләнгән.

Бюджет чараларын һәм дәүләт (муниципаль) милкен нәтиҗәсез файдалану.

«Татарстан Республикасы Милли музее» ДБМУ тарафыннан коммуналь хезмәтләр күрсәтүчеләрне чынбарлыктагы ихтыяждан артык аванслауда (аерым очракларда коммуналь хезмәтләргә чынбарлыктагы ике еллык ихтыяҗ күләмендә аванслау) чагылган 4 012,5 мең сум күләмендә Татарстан Республикасы бюджеты акчаларыннан нәтиҗәсез файдалануга юл куелган.

Хуҗалык итүче объектның финанс-хуҗалык эшчәнлеген тикшерү нәтиҗәләре буенча ачыкланган бозулар.

«Татарстан Республикасы геологиясе һәм җир асты байлыкларыннан файдалану буенча фәнни-җитештерү берләшмәсе» Дәүләт унитар предприятиесенең (алга таба –«Геоцентр» ДУП) финанс-хуҗалык эшчәнлеген тикшерү акча чараларының төп чыганагы булып Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы белән төзелгән контрактларны һәм килешүләрне үтәү кысаларында кергән акчалар торганы ачыкланды, аларга предприятие табышының 64 проценты, ягъни 34 млн. сум туры килә. Шул ук вакытта төзелгән дәүләт контрактларының шактый күләмнәренә карамастан, предприятие эшчәнлеге анализлана торган чорда чиста активларның бәясен 2 тапкыр диярлек (5,3 млн. сумнан 3 млн. сумга кадәр) киметүнең тискәре тенденциясе булу белән характерлана.

Югарыда күрсәтелгән хәлләр шул исәптән тикшерү барышында ачыкланган системалы бозулар һәм җитешсезлекләр белән дә аңлатылырга мөмкин. Шулай, Россия Федерациясе Гражданлык кодексының 295 маддәсенең 2 пунктын бозып, «Геоцентр» ДУП, Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы (предприятиене гамәлгә куючы) белән килештермичә генә, ел саен гомуми суммасы 515,6 мең сум булган дәүләт милкен исәптән

төшергән, шулай ук 500 мең сумлык процентсыз займ килешүе буенча заем акчалары җәлеп иткән.

«Геоцентр» ДУП эшчәнлегендә гомуми бәясе 1 853,8 мең сум булган ихтыяҗ булмаган мөлкәт (компьютер техникасы, кондиционерлар, автомобиль) булуы ачыкланды.

Ялган билгеләре булган документлар буенча хисап тотучы затларга чыгымнарны кайтаруның күпсанлы очраклары ачыкланды.

2020 елда Хисап палатасы үткәргән тикшерүләрнең нәтиҗәләре буенча бюджет акчаларын тотканда, республика, муниципаль милектән файдаланганда гомуми суммасы **3 158 947,6 мең сум** булган (тәртип бозуларның билгеләнгән күләменең 93,3 проценты) ачыкланган финанс бозуларны һәм җитешсезлекләрне бетерү буенча **чаралар күрелде**.

Хисап палатасы тарафыннан ачыкланган бозулар буенча министрлыклар һәм ведомстволар җитәкчеләренә, муниципаль берәмлекләр башлыкларына **41 күрсәтмә һәм 67 мәгълүмат хаты** җибәрелде.

Барлык тикшерү чаралары материаллары Татарстан Республикасы Прокуратурасына юлланды.

23 вазыйфаи зат административ җаваплылыкка тартылган, **гомуми суммасы 288 мең сум**, шул исәптән физик затларга – 248 мең сум, юридик затларга 40 мең сум күләмендә штраф салынган.

Хисап палатасы һәм прокуратура органнары күрсәтмәләре буенча **79 вазыйфаи зат** дисциплинар җаваплылыкка тартылган.

2 тикшерү чарасы – «Демография – Өлкән буын» илкүләм проектын тормышка ашыруга бүлеп бирелгән бюджет чараларын куллануны тикшерү һәм балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру һәм тәэмин итүгә бүлеп бирелгән бюджет чараларын куллануның нәтиҗәлелек аудиты нәтиҗәләре буенча идарәи карарлар кабул ителде.

Авыл җирендә яшәүче 65 яшьтән өлкәнрәк затларны Татарстан Республикасы медицина оешмаларына китерү тәртибенә (Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгының һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының уртак боерыгы) һәм Балалар һәм яшьләрнең ялын, сәламәтләндерүен оештыруны финанслау тәртибенә (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 29 апреленнән 346 номерлы карары) үзгәрешләр кертелде.

Экспертиза-аналитика эшчәнлеге

Хисап вакыт аралыгында уздырылган экспертиза-аналитика чаралары йомгаклары буенча түбәндәгелр әзерләнде:

- Татарстан Республикасы законнары проектларына 27 бәяләмә;

- Татарстан Республикасы дәүләт программасы проектына, дәүләт программасына кертелә торган үзгәрешләр проектына 2 бәяләмә;

- 2019 ел эчендә Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турында еллык хисапны тышкы тикшерү нәтиҗәләре буенча бәяләмә;

- 2019 ел эчендә Татарстан Республикасы ММИ Территориаль фонды бюджеты үтәлеше турында еллык хисапны тышкы тикшерү нәтиҗәләре буенча бәяләмә;

- 2020 елның 1 кварталында, 1 яртыеллыгында һәм 9 аенда Татарстан Республикасы бюджеты, Татарстан Республикасы ММИ Территориаль фонды бюджеты үтәлеше мониторингы нәтиҗәләре буенча 6 бәяләмә.

Закон проектларына бәяләмәләр проектлары Хисап палатасы Коллегиясендә карап тикшерелде һәм расланды.

Татарстан Республикасы территориясендә милли проектларны региональ өлешләрдә (алга таба – региональ проектлар) гамәлгә ашыру мәсьәләләре системалы рәвештә башлангыч, агымдагы һәм соңгы тикшерүләрне тормышка ашыру вакытында каралды. Региональ проектларны финанслауга, планлаштырылган максатчан күрсәткечләргә ирешүгә, аларны гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан норматив хокукый актларны үз вакытында кабул итүгә, федераль бюджеттан трансфертлар бирү шартларын үтәүгә анализ ясалды.

Дәүләт программаларын мониторинглау буенча эш дәвам итте, аның йомгаклары буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына программа чараларын үтәү нәтиҗәлелеге индикаторларын

билгеләүгә якын килү өлешендә программа-максатчан идарә системасын камилләштерү буенча тәкъдимнәр җибәрелде. Республика Республика премьер-министры кушуы буенча дәүләт заказчылары – Дәүләт программалары координаторлары тарафыннан нәтиҗәлелек күрсәткечләре составына төзәтмәләр кертү буенча эш башланды.

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 157 маддәсе, Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 47.1, 64 маддәләре нигезендә хисап елында **«2021 елга һәм 2022 һәм 2023 еллар планлы чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында»** Татарстан Республикасы законы проектына экспертиза үткәрелде. Экспертиза нәтиҗәләре буенча әзерләнгән бәяләмә законнарның нигезләмәләре буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советына юлланды. Татарстан Республикасы бюджеты проектының чираттагы елга һәм планлы чорга керемнәр һәм чыгымнар буенча тәкъдим ителә торган төп характеристикаларының нигезле булуы, республика бюджеты дефициты күләме, аны финанслау чыганаклары һәм дәүләт бурычына хезмәт күрсәтүгә тотылган чыгымнар күләменең билгеләнгән бюджет закончалыгы таләпләренә туры килүе билгеләп үтелде.

Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарының төп күләме программ форматта төзелгән, бу закончалык нигезләмәләре белән килешә. Экспертиза нәтиҗәләре буенча 2021-2023 елларга республика бюджетына раслаганнан соң бюджет ассигнованиеләре белән туры китерү максатында күрсәткечләрне 25 дәүләт программасы буенча тәгаенләштерү кирәклеге билгеләп үтелде.

Илкүләм проектлар составына керә торган региональ проектларны тормышка ашыруга каралган бюджет ассигнованиеләре күләме федераль дәрәҗәдә билгеләнгән финанслауда катнашу шартларын үтәүне тәэмин итә.

2021 елга ачык норматив йөкләмәләрне үтәүгә тотылырга ниятләнгән бюджет чыгымнары гамәлдәге норматив хокукый актлар

нигезендә һәм социаль ярдәм чаралары алучыларның саны буенча килеп чыккан динамиканы истә тотып төзелде.

Экспертиза нәтиҗәләре буенча аерым җитешсезлекләр ачыкланды. Аларны юкка чыгару максатында кире кайтарылмый торган керемнәрнең аерым юнәлешләре буенча Россия Федерациясе бюджет классификациясе кодларын тәгаенләштерергә, закон проектының аерым гыйбарәләрен Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезләмәләре белән тәңгәл китерергә, шулай ук планлы чорда республика бюджеты дефицитын финанслауның аерым чыганаклары атамасы өлешендә төзәтмәләр кертергә тәкъдим ителде.

Татарстан Республикасы бюджеты проектын Татарстан Республикасы Дәүләт Советында икенче укылышта карау барышында Хисап палатасы тәкъдимнәре исәпкә алынды.

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 145 маддәсе һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 47.1 маддәсе нигезләмәләре буенча **«2021 елга һәм 2022 һәм 2023 еллар планлы вакыт аралыгына Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фонды бюджеты турында»** Татарстан Республикасы законы проектына экспертиза үткәрелде. Экспертиза нәтиҗәләре буенча әзерләнгән бәяләмә Татарстан Республикасы Дәүләт Советына тапшырылды. 2021 елга һәм планлы вакыт аралыгына Татарстан Республикасы ММИ Территориаль фонды бюджеты параметрлары бюджет законнары нигезләмәләрен исәпкә алып формалаштырылган.

Бюджет классификациясендә билгеләнгән алымнарны үтәүне тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы ММИ Территориаль фонды белән идарә ителә торган закон проектына кушымталар рәвешендә раслана торган керемнәрнең һәм бюджет кытлыгын финанслау чыганакларының исемлеген тәгаенләштерергә тәкъдим ителде.

Татарстан Республикасы ММИ Территориаль фонды бюджеты проектын Татарстан Республикасы Дәүләт Советында икенче укылышта карау барышында Хисап палатасының тәкъдимнәре исәпкә алынды.

Хисап елында **«2020 елга, 2021 һәм 2022 еллар планлы вакыт аралыгына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү турында»** законнарының 3 проектына экспертиза үткәрелде һәм тиешле бәяләмәләр әзерләнде. Экспертиза нәтиҗәләре буенча кертелә торган төзәтмәләр һәм өстәмәләрнең нигезле булуы, шулай ук бюджет законнары белән билгеләнгән чикләүләрне саклау расланды.

Шулай ук **«2020 елга, 2021 һәм 2022 еллар планлы вакыт аралыгына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминиятләштерүе фонды бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү турында»** законнарының 3 проектына экспертиза үткәрелде. Составы һәм эчтәлеге буенча закон проектлары бюджет законнары таләпләренә туры килә дип билгеләп үтелде. Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминияте территориаль фондының нормалаштырылган иминият запасы чаралары зурлыгы һәм аны юллау юнәлешләре 2010 елның 29 ноябреннән «Россия Федерациясендә мәҗбүри медицина иминияте турында» 326-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләрен исәпкә алып төзәтелде.

«2019 елга Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турында» һәм **«2019 елга Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминиятләштерүе фонды бюджеты үтәлеше турында»** Татарстан Республикасы законнары проектларына экспертиза нәтиҗәләре буенча закон проектлары күрсәткечләренең Татарстан Республикасы бюджеты һәм Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фонды бюджеты үтәлеше турында еллык хисапларның күрсәткечләренә туры килүе расланды. Бәяләмәләрдә законнар проектлары һәм аларга

кушымталарның составы һәм эчтәлеге буенча бюджет законнарында билгеләнгән таләпләрне үтәп формалаштырылуы билгеләп үтелде.

2020 елда Татарстан Республикасының түбәндәге законнары проектларына экспертизалар үткәрелде:

- «Оешмалар милкенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 2 маддәсенә үзгәреш кертү турында;

- «Оешмалар милкенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 3 маддәсе 2 өлешенең 14 пунктына үзгәреш кертү турында;

- «Оешмалар милкенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 3 маддәсенә үзгәреш кертү турында;

- «Оешмалар милкенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 5 маддәсенә үзгәреш кертү турында;

- «Салым салуның гадиләштерелгән системасын кулланучы салым түләүчеләр өчен дифференциацияләнгән салым ставкаларын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү турында» (2 закон проекты);

- «Салым түләүчеләрнең аерым категорияләре өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 1 маддәсенә үзгәреш кертү турында»;

- «Татарстан Республикасының монопрофильле муниципаль берәмлекләре (моношәһәрләре) территорияләрендә төзелгән алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территорияләре резидентлары өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 1 маддәсенә үзгәрешләр кертү турында»;

- «Татарстан Республикасы территориясендә салым салуның патент системасын кертү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү турында» (2 закон проекты);

- «2021 елга Татарстан Республикасында хезмәт базары үзенчәлекләрен чагылдыра торган региональ коэффициентны билгеләү турында»;

- «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында»;

- «Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 41 маддәсенә үзгәрешләр кертү турында»;

- «Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына 2020 елгы Бөтенроссия халык санын алуны әзерләү һәм уздыру буенча Россия Федерациясе вәкаләтләрен бирү турында»;

- «2021 елга Татарстан Республикасында мәктәпкәчә белем бирү буенча белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында»;

- «2021 елга Татарстан Республикасында гомуми белем бирү һәм һөнәри белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем, шулай ук өстәмә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында».

Закон проектлары Россия Федерациясе субъекты законнарында билгеләнгән вәкаләтләр кысаларында, шулай ук федераль дәрәҗәдә законнарга үзгәрешләр кертү белән бәйле рәвештә эшләнгән.

«Оешмалар милкенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 2 маддәсенә үзгәреш кертү турында», «Оешмалар милкенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 3 маддәсендәге 2 өлешенең 14 пунктына үзгәрешләр кертү турында», «Салым салуның гадиләштерелгән системасын кулланучы салым

түләүчеләр өчен дифференциацияләнгән салым ставкаларын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү турында» закон проектларына бәяләмәләрдә Татарстан Республикасы бюджетының төшеп калу ихтималы булган керемнәренә бәйле агымдагы ел бюджетының баланслылыгы югалу куркынычы билгеләп үтелде.

«Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына 2020 елгы Бөтенроссия халык санын алуны әзерләү һәм уздыру буенча Россия Федерациясе вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы законы проектына финанс-икътисадый экспертиза нәтиҗәләре буенча әлеге вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль берәмлекләр бюджетларына бирелә торган субвенцияләр күләмен билгеләү методикасының Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына күрсәтелгән максатларга чаралар бирү өчен федераль дәрәҗәдә кабул ителгән алымга туры килүе билгеләнде. Шулай ук Хисап палатасын 2020 елгы Бөтенроссия халык санын алуны әзерләгәндә һәм үткәргәндә барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләрен тормышка ашыру кысаларында тикшереп торуны гамәлгә ашыра торган органнар исемлегенә кертү өчен нигезләрнең булуы билгеләп үтелде.

«**2021 елга Татарстан Республикасында мәктәпкәчә белем бирү буенча белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль мәгариф оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында»** һәм **«2021 елга Татарстан Республикасында гомуми белем бирү һәм һөнәри белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем, шулай ук өстәмә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт**

гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында» Татарстан Республикасы законнары проектларына экспертиза нәтиҗәләре буенча бәяләмәләрдә 2021 елга финанс белән тәэмин итү нормативларының гамәлдәге закон нигезләмәләре буенча формалашуы билгеләп үтелде. Раслауга тәкъдим ителә торган нормативлар Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт социаль сәясәтен гамәлгә ашыру чаралары турында»гы Указы белән билгеләнгән белем бирү оешмаларының педагогик хезмәткәрләренең хезмәт хакы дәрәҗәсенә ирешү буенча бурычларны исәпкә алып билгеләнгән.

Хисап чорында **«2023-2030 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасындагы башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү»** дәүләт программасы проектына (алга таба – 2023 – 2030 елларга Программа проекты) һәм **«2014-2022 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасындагы башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү»** Татарстан Республикасы дәүләт программасына кертелә торган үзгәрешләр проектына (алга таба – 2014-2020 елларга Программага үзгәрешләр проекты) финанс-икътисадый экспертиза үткәрелде.

2023-2030 елларга Программа проектына экспертиза нәтиҗәләре буенча түбәндәгеләр тәкъдим ителде:

- республиканың башка дәүләт программалары чаралары белән мәгънәсе буенча тәңгәллек фактлары булуга бәйле рәвештә программа чараларының исемлеген тәгаенләргә;

- дәүләт программасын тормышка ашыру барышын тикшереп торуны гамәлгә ашыру өчен өстәмә шартлар тудыру максатыннан, аларны тормышка ашыру өчен финанс ресурслары күләмен нәтиҗәлелек күрсәткечләре белән бәйләп, чараларны детальләштерергә;

- аерым программа юнәлешләре буенча финанслауның соңгы күләмнәрен тәгаенләштерергә.

2014-2022 елларга Программага үзгәрешләр проектына экспертиза нәтиҗәләре буенча аерым чаралар буенча түбәндәгеләр билгеләнде:

- күрсәткечләрнең дәвамчанлыгы тәэмин ителмәгән – 2020 елга планлаштырыла торган күрсәткечнең кыйммәте алдагы елның ирешелгән дәрәҗәсеннән түбәнрәк;

- чараларның берсе буенча раслауга тәкъдим ителә торган финанслау күләме исәп-хисап белән расланмаган;

- 2 күрсәткеч буенча 2020 елга финанслауның йомгаклау күләме арифметик исәпләү аша алына торган саннар белән туры килми.

Хисап палатасының тиешле бәяләмәләре Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына юлланды.

Татарстан Республикасы бюджетының һәм Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фонды бюджетының агымдагы үтәлешен тикшерү мониторинг рәвешендә гамәлгә ашырылды, алар салым һәм салым булмаган керемнәр, кире кайтарылмый торган керемнәрнең керүен, чыгым йөкләмәләренең үтәлешен, узган елның шул ук күрсәткечләре белән чагыштырганда бюджетлар үтәлешенең төп күрсәткечләренең динамикасын анализлау, бюджет кытлыгын финанслау чыганакларыннан җәлеп ителә торган чаралар күләмен бәяләү, бюджет турындагы законнарның текст маддәләрен үтәү, законнарны үтәүне үз эченә алган.

2020 елда республика бюджетын үтәгәндә Татарстан Республикасы Бюджет кодексы белән билгеләнгән бюджет кытлыгы, дәүләт бурычына хезмәт күрсәтү чыгымнары күләме буенча чикләүләр үтәлгән. Чыгым йөкләмәләре бюджет йөкләмәләренең җиткерелгән лимитлары чикләрендә кабул ителде, социаль әһәмияткә ия чыгымнар үз вакытында гамәлгә ашырылды. Федераль проектларның региональ өлешен финанслау һәм федераль бюджеттан илкүләм проектларны гамәлгә ашыруга максатчан чаралар бирү шартларын үтәү тәэмин ителде.

Мониторинг нәтиҗәләре Хисап палатасының 2020 елның 1 кварталында, 1 яртыеллыгында һәм 9 ае эчендә Татарстан Республикасы бюджеты һәм Татарстан Республикасы ММИ Территориаль фонды бюджеты үтәлеше турындагы бәяләмәләрендә чагылдырылган. Закон нигезләмәләре буенча Хисап палатасы бәяләмәләре Татарстан Республикасы Дәүләт Советына тапшырылды.

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 149, 264.4 маддәләре һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 97.3, 97.6 маддәләре нигезләмәләрен гамәлгә ашырып, хисап елында **2019 ел өчен Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турындагы хисапның** тулылыгын һәм дөреслеген бәяләү максатларында тышкы тикшерү үткәрелде.

Закон нигезләмәләре буенча тышкы тикшерү кысаларында бюджет чараларының 40 төп администраторының еллык бюджет хисаплылыгы анализланды.

Бәяләмәдә тышкы тикшерүгә тапшырылган 2019 ел өчен республика бюджеты үтәлеше турында Хисапның, шулай ук бюджет чараларының баш администраторларының еллык бюджет хисаплылыгының Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары үтәлеше турында хисапларны төзү һәм тапшыру тәртибен көйләүче норматив хокукый актлар таләпләрен исәпкә алып һәм 2019 елга расланган бюджет классификациясе кодлары буенча формалаштырылуы билгеләп үтелә.

2019 елга республика бюджеты үтәлеше турындагы Хисап күрсәткечләре Татарстан Республикасы бюджеты баш администраторларының еллык бюджет хисаплылыгы күрсәткечләре белән расланган.

Республика бюджеты гамәлдәге законнарны саклап башкарылган, 2019 ел өчен бюджет үтәлеше турындагы Хисап күрсәткечләренең закон белән расланган билгеләнешләрдән тайпылышы объектив

характерга ия, аларның сәбәпләре бюджет законнары белән билгеләнгән сәбәпләргә туры килгән.

Дәүләт программаларының, шулай ук төбәк проектларының 2019 елга билгеләнгән нәтиҗәлелек күрсәткечләренә ирешелүенә бәя бирелде. Расланган индикаторларны үтәү дәрәҗәсенә йогынты ясаган сәбәпләргә анализ ясалды. Нәтиҗәләр бәяләмәдә чагылыш тапкан.

Шулай ук **2019 ел өчен Татарстан Республикасы ММИ Территориаль фонды бюджеты үтәлеше турындагы Хисапны** тикшерү уздырылды.

2019 ел өчен еллык хисапта Татарстан Республикасы ММИ Территориаль фонды бюджеты үтәлеше турында белешмәләрнең дөрес яки тулы булмавы билгеләнмәде.

Тиешле бәяләмәләр Татарстан Республикасы Дәүләт Советына, Татарстан Республикасы Президентына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына тапшырылды.

Эшчәнлекне методологик яктан тәэмин итү

Хисап палатасына йөкләнгән вәкаләтләрен гамәлгә ашыру максатларында хисап елында аның эшчәнлеген методологик яктан тәэмин итү буенча эш дәвам иттерелде.

Хисап палатасы эшчәнлеген оештыру һәм тышкы дәүләт финанс тикшерүе стандартлары актуальләштерелде:

- «Тикшерү чарасын үткәрүнең гомуми кагыйдәләре»;
- «Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше барышын оператив тикшерүне уздыру»;
- «Татарстан Республикасы Мәҗбүри медицина иминиятләштерүе территориаль фонды бюджеты үтәлеше барышын оператив тикшерү уздыру»;
- «Татарстан Республикасы Хисап палатасы хисапларын әзерләү».

Күрсәтелгән документларның яңа редакцияләрендә бюджет законнарына кертелгән үзгәрешләр исәпкә алынды. Моннан тыш, «Тикшерү чарасын үткәрүнең гомуми кагыйдәләре» стандарты Хисап палатасы вазыйфаи затларының тикшерү чараларда катнашканда шәхси кызыксынуы барлыкка килү куркынычын һәм алшартлар булдырмауга һәм кире кайтаруга юнәлдерелгән нигезләмәләр белән тулыландырылды.

Россия Федерациясе Хисап палатасы, Россия Федерациясе Хисап палатасы каршындагы Тикшерү-хисап органнары советы, Россия Федерациясе субъектларының тикшерү-хисап органнары белән үзара хезмәттәшлек

2020 елда Хисап палатасы Россия Федерациясе Хисап палатасы, Россия Федерациясе Хисап палатасы каршындагы Тикшерү-хисап органнары советы (алга таба – Совет), региональ тикшерү-хисап органнары белән хезмәттәшлекне үстерү һәм ныгыту буенча эшен дәвам иттерде.

Совет Президиумы әгъзасы, Хисап палатасы Рәисе А.И. Демидов Мәскәүдә Россия Федерациясе Хисап палатасы Коллегиясенең 25 еллыгына багышланган киңәйтелгән утырышында катнашты. Дәүләт аудитының югары органы эше йомгаклары һәм эшчәнлекнең алдагы өстенлекле юнәлешләре буенча фикер алышу булган тантаналы чара

Россия Федерациясе Президенты Администрациясе җитәкчесенең беренче урынбасары С.В. Кириенко, Россия Федерациясе Федераль җыелышы Федерация Советы Рәисе В.И.Матвиенко, Россия Федерациясе Федераль Җыелышы Дәүләт Думасы Рәисенең беренче урынбасары А. Д. Жуков, Россия Федерациясе Финанс министры А.Г. Силуанов, Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе урынбасары Т.А. Голикова, Мәскәү мэры С.С. Собянин катнашында узды.

Хисап палатасы Рәисе А.И. Демидов җитәкләгән Идел буе федераль округында Совет Бүлегенең эш планы нигезендә видеоконференция режимында Ульяновск өлкәсе Хисап палатасы тарафыннан «Илкүләм проектларны тормышка ашыру барышында

муниципаль тикшерү-хисап органнарының эшчәнлеге» темасына төбәкара түгәрәк өстәл оештырылды. Россия Федерациясе Хисап палатасы, тышкы финанс тикшерүенең региональ һәм муниципаль

органнары вәкилләре катнашында тикшерүнең хокукый, методологик, мәгълүмати тәэмин ителеше мәсьәләләре каралды, тәмамланган тикшерүләр һәм экспертиза-аналитика чаралары нәтиҗәләре буенча төп бозулар турында фикер алыштылар. Хисап палатасы аудиторы И.А. Мөбарәков Татарстан Республикасы территориясендә илкүләм проектларны гамәлгә ашыруны тикшереп тору эшен оештыру, Хисап палатасының бу юнәлеш буенча методологик якын килүләре турында доклад белән чыгыш ясады.

Шулай ук видеоконференция режимында Самара өлкәсе Хисап палатасы тарафыннан «Илкүләм проектларны анализлауның төп инструментлары» темасына төбәкара түгәрәк өстәл оештырылды. Россия Федерациясе Хисап палатасы, региональ һәм муниципаль тышкы финанс тикшерүе органнары вәкилләре, Хисап палатасы аудиторы А.А. Якупов әлеге мәсьәлә буенча эш тәҗрибәсе белән уртаклаштылар.

Хисап елында Хисап палатасы Россия Хисап палатасы Россия Федерациясе субъектларының тикшерү-хисап органнары рәисләре, аудиторлары һәм инспекторлар составы өчен видеоконференция режимында үткәргән укыту семинарлары циклында катнашты.





Дистанцион укыту кысаларында түбәндәге актуаль мәсьәләләр каралды: стратегик аудит үткәрүгә методологик карашлар; дәүләт идарәсенең нәтиҗәлелеген, дәүләт аудиты өлкәсендә ачыклык булуны үстерүдә һәм нәтиҗәлелеген күтәрүдә цифрлы технологияләрне куллану; төбәк тикшерү-хисап органнары белән берлектә Россия Федерациясе Хисап палатасының «Экология» илкүләм проектын тормышка ашыруга аудит» экспертиза-аналитика чарасын оештыру һәм уздыру; бюджет чараларын куллану нәтиҗәлелегенә аудит оештыру һәм үткәрүнең гамәли аспектлары, бюджет чаралары администраторларының исәп-хисап һәм хисаплылыгы аудиты, төзелеп бетмәгән төзелеш объектларын тикшереп тору h. б.

Моннан тыш, «Торак сәясәте, торак-коммуналь хуҗалык, уңайлы шәһәр мохите: күрсәтелгән өлкәләрдә аудит үзенчәлекләре» темасына Россия-Кытай семинарында һәм «Дәүләт сатып алулары өлкәсендә аудит: алымнарны камилләштерү һәм тикшерүләр үткәрү практикасы» темасына Россия – Белорусия семинарында катнаштылар.

Хисап палатасы аудиторы А.А. Якупов Махачкалада узган Россия Федерациясе субъектларының тикшерү-хисап органнарының тәмамланмаган төзелеш объектларын тикшерүдә тоту мәсьәләләре

буенча Бөтенроссия киңәшмәсендә катнашты һәм Хисап палатасы тарафыннан төзелеп бетмәгән төзелеш күләмен киметү өчен кабул ителә торган чараларның нәтиҗәлелеге мәсьәләләре буенча тематик тикшерү чаралары үткәрү тәҗрибәсе турында чыгыш ясады.

Хисап палатасы аудиторы С.Е. Колодников Мәскәүдә узган VIII Васильев укуларында – ел саен үткәрелә торган «Җәмәгать

финанслары: фән һәм практика» форумында катнашты. Чара икътисад һәм иҗтимагый секторның финанслары өлкәсендә фәнни-гамәли фикер үсешен стимуллаштыру максатларында үткәрелә. Семинар барышында гражданнарның тормыш сыйфатын күтәрү алымнары, инструментлары һәм бу юнәлештә эш нәтиҗәләре каралды. Чыгышларны Федераль казначылык җитәкчесе Р.Е. Артюхин, Россия Федерациясе финанс министры урынбасары А. М. Лавров, Россия Федерациясе Федераль Җыелышы Дәүләт Думасының Бюджет һәм салымнар буенча комитеты рәисе урынбасары Н. С. Максимова һәм башкалар ясады.

Хисап елында Хисап палатасында Хисап палатасы Рәисе А.И. Демидовның Камчатка крае һәм Севастополь шәһәре тикшерү-хисап органнары җитәкчеләре С. В. Лозовский һәм Ю.В.Кокарева белән эшлекле очрашуы оештырылды. Киңәшмә барышында яңа коронавирус инфекциясе таралуга каршы көрәш чараларын тормышка ашыруга юнәлтелгән бюджет акчаларын тотуны тикшерүнең актуаль

мәсьәләләре, шул исәптән Татарстан Республикасы Хисап палатасы һәм Россия Федерациясе Хисап палатасының «Яңа коронавирус инфекциясе ачыкланган гражданнарга һәм яңа короновирус инфекциясе йоктыру куркынычы булган затларга медицина ярдәме күрсәтүче медицина хезмәткәрләренә аерым хезмәт шартлары һәм өстәмә нагрузка өчен стимуллаштыру характерындагы федераль түләүләрне гамәлгә ашыру мониторингы» параллель тикшерү чарасы нәтиҗәләре буенча фикер алыштылар.

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре тикшерү-хисап органнары белән хезмәттәшлек

Хисап палатасы Татарстан Республикасы Тикшерү-хисап органнары Советы эшчәнлеге кысаларында муниципаль тикшерү-хисап органнары белән хезмәттәшлекне тәэмин итү буенча эшен дәвам итте.

Муниципаль тикшерү-хисап органнарына тикшерү-ревизия һәм экспертиза-аналитика эшчәнлегенең төп юнәлешләре буенча оештыру, хокукый, методик, мәгълүмати ярдәм күрсәтелде. Барлык муниципаль районнар һәм шәһәр округларының тикшерү-хисап органнарына кураторлар – аудиторлар һәм Хисап палатасының структур бүлекчәләре җитәкчеләре беркетелде.

Ай саен муниципаль берәмлекләрнең тикшерү-хисап органнары эшчәнлегенә мониторинг ясалды.

Хисап вакыт аралыгында Хисап палатасы Татарстан Республикасының муниципаль тикшерү-хисап органнары белән түгәрәк өстәл оештырды, аның барышында җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре өлкәсендәге актуаль мәсьәләләр, шулай ук илкүләм проектларны тормышка ашыруда муниципаль берәмлекләрнең роле турында фикер алыштылар. Чыгышлар белән Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министры Ф.А. Әһлиуллин һәм Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы вәкиле чыкты.

Шулай ук муниципаль берәмлекләрнең тикшерү-хисап органнары Халыкара коррупциягә каршы көрәш көне алдыннан Хисап палатасы оештырган «Дәүләт гражданлык хезмәтендә мәнфәгатьләр конфликты» темасына видеоконференция режимында семинар-киңәшмәдә катнаштылар.

Дәүләт һәм муниципаль хезмәттә мәнфәгатьләр каршылыклары килеп чыгу, шулай ук аларны җайга салу практикасы турында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, В.Г. Тимирясов исемендәге Казан инновация университеты профессоры И.И. Бикеев һәм Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсе вәкиле сөйләделәр.

Дәүләт һәм муниципаль финанс тикшерүенең актуаль мәсьәләләре буенча алдынгы һөнәри тәҗрибәне өйрәнү максатыннан республика муниципаль берәмлекләренең тикшерү-хисап органнары вәкилләренең видеоконференция форматында Россия Федерациясе Хисап палатасының укыту семинарларында катнашуы оештырылды.

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм хокук саклау органнары белән хезмәттәшлек

Хисап палатасы Рәисе А.И. Демидов җитәкчелегендәге Татарстан Республикасында Дәүләт финанс тикшерүе мәсьәләләре буенча Ведомствоара координацияләү советы (алга таба – Ведомствоара координацияләү советы) эшчәнлеге кысаларында хисап елында финанс тикшерүе органнары һәм хокук саклау органнарының үзара хезмәттәшлеген үстерү буенча эш дәвам итте.

Ведомствоара координацияләү советы Дәүләт (муниципаль) финанс тикшерүе органнары ачыклаган бозуларны һәм җитешсезлекләрне анализлау һәм системалаштыру нәтиҗәләре буенча бәяләмә әзерләде һәм хуплады, ул финанс-бюджет өлкәсендә хокук бозуларны кисәтү һәм профилактикалау максатларында министрлыкларга, ведомстволарга һәм муниципаль берәмлекләргә җибәрелде.

Ел саен ведомствоара координацияләү советы әгъзалары тарафыннан эштә кабатлануны булдырмау максатларында Тикшерү чараларының җыелма планы төзелде һәм расланды.

Квартал саен ачыкланган бозулар буенча оператив мәгълүмат бирү һәм чаралар күрү максатында органнар үткәргән, Ведомствоара координацияләү советында тәкъдим ителгән тикшерү чараларының нәтиҗәләре турында җыелма мәгълүмат Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрелде.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанслар һәм Икътисад, инвестицияләр һәм эшмәкәрлек комитетларының берләштерелгән утырышында Хисап палатасы аудиторы А.Р. Вәлиев катнашты, анда ул республика Парламенты йөкләмәсе буенча 2016-2019 елларда Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына субсидияләр бирү өчен бүлеп бирелгән бюджет акчаларын файдалану

мәсьәләләре буенча үткәрелгән тикшерү нәтиҗәләре буенча чыгыш ясады.

Шулай ук Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Бюджет, салымнар һәм финанслар һәм социаль сәясәт буенча комитетлары утырышларында Хисап палатасы аудиторы И.А. Мөбарәков катнашты, анда Татарстан Республикасы Дәүләт Советы йөкләмәсе буенча үткәрелгән 2016-2019 елларда балалар һәм яшьләрнең ялын тәэмин итүгә һәм оештыруга бүлеп бирелгән Татарстан Республикасы бюджеты чараларын куллануның нәтиҗәлелек аудиты нәтиҗәләрен тәкъдим итте. Хисап палатасы йомгаклары нигезендә профильле министрлыкларга алга таба закон нормаларын бозуларны булдырмау буенча чаралар күрергә тәкъдим ителде. Социаль сәясәт комитеты әгъзалары шулай ук Татарстан Республикасында балалар ялын оештыру турында закон проектын эшләү турында карар кабул иттеләр.

Хисап елында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы утырышында депутатлар бертавыштан яңа вәкаләтләр срогына Хисап палатасы Рәисе вазыйфасына билгеләп кую өчен А.И. Демидов кандидатурасын хупладылар. Хисап палатасы аудиторлары вазыйфасына бертавыштан С.Е. Колодников, И.А. Мөбарәков һәм А.А. Якупов расланды.

Казан (Идел буе) федераль университетының Дәүләт һәм муниципаль идарә югары мәктәбе белән хезмәттәшлек кысаларында Хисап палатасы вәкилләре 2020 елда Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү курсларында катнаштылар.

Эштә хәбәрдарлык

2020 елда Хисап палатасы, Татарстан Республикасында Дәүләт финанс тикшерүе мәсьәләләре буенча ведомствоара координацияләү советы һәм Татарстан Республикасы Тикшерү-хисап органнары советы эшчәнлеге массакүләм мәгълүмат чараларында (интернет-басмаларда, газета, журналларда, телевидениедә) даими яктыртылып торды.

Хисап чорында Хисап палатасы эшчәнлеге 114 материалда, шул исәптән федераль һәм региональ басмаларда: «РБК», «Татар-информ» мәгълүмат агентлыкларының веб-сайтларында, «Вечерняя Казань», «БизнесOnline» һәм «Реальное время» электрон газеталарында, «Idel.Реалии», «Клуб регионов» веб-сайтларында, «Mail.Ru» интернет-порталында, «Аргументы и Факты», «Коммерсант» газеталарының төбәк басмаларында, «Татарстан» журналында, «Татарстан24», «Татарстан» һәм «ТНВ» телеканалларының яңалыклар чыгарылышларында тәкъдим ителгән.

Хисап палатасы эшчәнлеге турында мәгълүмат шулай ук рәсми сайтта (https://sprt.ru), Россия Федерациясе Хисап палатасы һәм Россия Федерациясе тикшерү-хисап органнары порталында (https://portalkso.ru) урнаштырылган. 2020 елда Хисап палатасы сайтына 23 619 керү теркәлгән.

Үткәрелгән тикшерү чаралары нәтиҗәләре буенча йомгаклау документлары, Хисап палатасы эшчәнлеге хроникасы квартал саен Хисап палатасының мәгълүмати бюллетеньнәрендә бастырып чыгарылды, алар Татарстан Республикасы Президентына, Татарстан Республикасы Дәүләт Советына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, Татарстан Республикасында Дәүләт финанс тикшерүе мәсьәләләре буенча ведомствоара координацияләү советы әгъзаларына җибәрелде.